**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структурасына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеген Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты составыннан чыгарырга һәм аны Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең мөстәкыйль структур бүлекчәсе дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге турында» 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-889 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 22 ноябрендәге ПУ-1016 номерлы, 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы, 2018 елның 1 октябрендәге ПУ-700 номерлы, 2022 елның 11 февралендәге ПУ-112 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 10 маендагы 285 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы дәүләт органнарында аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле $20^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$20^1$. «Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге мөдире.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 15 мартындагы 162 номерлы, 2023 елның 23 декабрендәге 902 номерлы һәм 2023 елның

26 декабрендәге 911 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктның унтугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге.»;

в) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына – кушымта нигезендә (хезмәт урынында файдалану өчен).

4. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе регламентын раслау турында» 2024 елның 20 гыйнварындагы 44 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе регламентына, 3.8 пунктның өченче абзацыннан «Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа билгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 66 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа билгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле $21^1$ пункт өстәргә:

«$21^1$. Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге мөдире.»;

б) 68 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә аларны билгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау

турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 67 номерлы боерыгы нигезендә расланган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә аларны биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә, түбәндәге эчтәлекле 21[1] пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«21[1]. «Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге мөдире.».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Администрациясе Җитәкчесенә:

әлеге Указны гамәлгә ашыру буенча кирәкле оештыру-штат чараларын законнар нигезендә уздырырга;

билгеләнгән тәртиптә 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге турында нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты турында нигезләмәгә тиешле үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне раслауга бирергә.

9. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 30 март
№ 232